КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 февраль

г.Казань

№ 154

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 31 август, 746 нчы; 2013 ел, 14 март, 160 нчы; 2013 ел, 29 август, 611 нче; 2014 ел, 28 март, 194 нче; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1001 нче; 2016 ел, 7 октябрь, 725 нче; 2017 ел, 15 август, 581 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 953 нче; 2018 ел, 31 май, 411 нче; 2019 ел, 15 гыйнвар, 4 нче; 2020 ел, 3 март, 162 нче; 2020 ел, 21 апрель, 310 нчы, 2020 ел, 27 июль, 627 нче, 2021 ел, 01 октябрь, 942 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1358 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчада:

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“урман фонды җирләрендә урманнарны саклауны (шул исәптән янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны һәм урман янгыннарын сүндерүне,

моңа урман янгыннарын локальләштерү һәм бетерү максатларында шартлату эшләрен үтәү һәм урман янгыннарын сүндерү максатларында явым-төшемне ясалма булдыру чараларын гамәлгә ашыру керми), урманнарны яклауны (урманны яклау районыннан һәм дәүләт урман патологиясе мониторингыннан тыш), урманнарны торгызуны (урман орлыкландырудан тыш, урман үсемлекләре орлыкларының федераль фондын һәм урманнарны яңадан торгызуга дәүләт мониторингы фондын төзүдән тыш), урман үрчетүне, шул исәптән:”;

унбишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

егерме беренче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

егерме икенче абзацка «, урман сагы» сүзләрен өстәргә;

илленче абзацта «, расланган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштыра һәм, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр бирелгән федераль башкарма хакимият органына бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек яисә гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләре системасын кулланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә" сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«урман фонды җирләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү башкарылган очракта, урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланганда урман законнары нигезендә аларда төзелешкә рөхсәт ителә торган капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирә, шулай ук күрсәтелгән объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирә.»;

$3.3.1^1$ пунктчада:

өченче абзацта «4 өлеш» сүзләрен «3 өлешә» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.2 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясындагы 2 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән җирләрдә урнашкан кишәрлек урманчылыклары составында төзелүче урманчылыкларны (төбәк әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территорияләренә карата) төзү, бетерү турында, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү хакында тәкъдимнәр кертә;

Татарстан Республикасы милкендәге урманнарга һәм урман кишәрлекләренә карата урман корылышы чараларын гамәлгә ашыра.».

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктының унынчы һәм унберенче абзацлары 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә;

бу карарның 1 пунктының җиденче абзацы 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин